РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село
Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән
авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

«02» апреля 2026 г. № 37

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджеты резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджеты резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турындагы нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджеты резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2007 елның 28 маендагы 68 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты житәкчесенә йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т.Айбатов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Советы карарына
кушымта
02.04.2026 ел №37

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджеты резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турындагы нигезләмә**

1. Чирмешән муниципаль районы бюджетының чыгым өлешендә резерв фонды (алга таба - Резерв фонды) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 маддәсе нигезендә көтелмәгән чыгымнарны, шул исәптән агымдагы финанс елында табигый бәла-казалар һәм башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерү буенча авария-торгызу эшләрен башкаруны финанслау өчен төзелә.

2. Резерв фонды күләме тиешле елга бюджетны раслаганда муниципаль район Советы тарафыннан билгеләнә һәм муниципаль район бюджетының расланган чыгымнарының 3% нан артмаска тиеш.

3. Резерв фонды акчалары түбәндәгеләрне финанслауга тотыла:

- көтелмәгән чыгымнар, шул исәптән Чирмешән районында табигый бәла-казалар һәм башка гадәттән тыш хәлләр зыяннарын бетерү буенча авария-торгызу эшләрен башкаруга;
- агымдагы финанс елында булган табигый бәла-казалар һәм янгыннар нәтиҗәсендә торак урыннары зыян күргән гражданнарга (торак урыннарның милекчеләренә, яллаучыларына) табигый бәла-казалардан һәм янгыннардан зарар күргәндә бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм түләү;
- иҗтимагый оешмалар һәм берләшмәләр;
- район әһәмиятендәге чаралар үткәрү;
- җирле әһәмияттәге проблемалар буенча очрашулар, симпозиумнар, күргәзмәләр һәм семинарлар үткәрү;
- Чирмешән муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнгән аерым муниципаль оешма һәм учреждениеләр хезмәткәрләренә, гражданнарга һәм озакка сузылган авыру очракларында, табигый бәла-казалардан һәм янгыннардан зыян күргәндә бер тапкыр бирелә торган премияләр түләү;
- муниципаль оешмалар һәм учреждениеләр заявкалары буенча ремонт һәм торгызу эшләрен башкару;
- махсус хәрби операция зонасында хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләр ихтыяҗлары өчен, Донецк Халык Республикасының, Луганск Халык Республикасының, Херсон һәм Запорожье өлкәләренең яңа территорияләрендә

объектларны торгызу өчен кирәкле төзелеш материаллары, хуҗалык, азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарлар белән тәэмин итү.

- район бюджетында чыгымнарның тиешле статьясы буенча каралган акчалар җитәрлек булмаган очракта, хезмәткә һәм кызыксындыру характерындагы түләүләргә, шул исәптән район муниципаль учреждениеләренең штаттан тыш хезмәткәрләренә дә.

- шәхси ярдәмче хуҗалыкка ярдәм итүгә субсидияләр түләү;

- бала туу уңаеннан бер мәртәбә пособие түләү;

- алдынгы механизаторларга бүләкләү түләү.

4. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акча бүлеп бирү турындагы күрсәтмәләре Чирмешән муниципаль районы башкарма-боеру органнары һәм оешмалары карамагындагы акчалар җитәрлек булмаган очракларда кабул ителә. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акча бүлеп бирү турындагы күрсәтмәсендә ассигнованиеләрнең гомуми күләме һәм аларны алучылар һәм үткәрелә торган чаралар буенча бүлү күрсәтелә. Акчаларны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты күрсәтмәләрендә каралмаган максатларга куллану рөхсәт ителми.

5. Резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турында Башкарма комитет күрсәтмәләре проектларын, бүлеп бирелә торган акчаларның күләмен һәм аларны тоту юнәлешен күрсәтеп, кабул ителгән гаризалар буенча һәм Башкарма комитет җитәкчесе кушуы буенча Финанс-бюджет палатасы әзерли.

6. Резерв фондыннан акча алуга дәгъва кылучылар Финанс-бюджет палатасына сорала торган акчаларның күләмен нигезләп, проектларны һәм смета-финанс исәп-хисапларын да кертеп, шулай ук кызыксынган органнарның бәяләмәсе кирәк булган очракта документлар тапшыралар.

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының җирле үзидарә органнары, юридик затлар резерв фондыннан акча бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгать белән бергә Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә (алга таба – Башкарма комитет җитәкчесе) күрсәтелгән максатларга чыгымнарның кирәклеген, кичектергесезлеген һәм көтелмәгәнлеген раслаучы документлар (шул исәптән китерелгән зыян турында органнарның белешмәләре йә таләп ителә торган акчалар күләмен нигезли торган документлар, шул исәптән смета-финанс исәп-хисаплары һәм проект-смета документациясе) тапшыралар.

Мөрәҗәгать итүчеләр-физик затлар түбәндәге документлар исемлеген тапшыралар:

1) Гариза;

2) Шәхесне таныклаучы документлар:

- паспорт;

- вакытлыча шәхес таныклыгы;

- туу турында таныклык - 14 яшькә җитмәгән балигъ булмаган гаилә әгъзалары өчен;

3) шәхси счетның иминият номеры;

4) Гаилә хәленә карап никахлашу турында таныклык (яисә никахны өзү турында таныклык);

5) Пенсия таныклыгы;

6) Инвалидлык турында белешмә (ВТЭК);

7) ЕГРНнан өземтә, гаилә составы һәм матди-көнкүреш хәле турында белешмә;

8) Һәр гаилә әгъзасы (ялгыз яшәүче граждан) тарафыннан акчалата алынган мөрәҗәгать итү аена кадәрге өч ай өчен керемнәр (хезмәт эшчәнлегеннән керемнәр булмау факты эштән китүе турында язулы хезмәт кенәгәсе белән раслана) турында белешмәләр;

9) Гаиләнең яисә ялгыз яшәүче гражданның башка керемнәре турында белешмә, аларга түбәндәгеләр керә:

- хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе Эчке эшләр органнары, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары, Россия Федерациясе таможня органнары һәм хокук саклау хезмәтенең башка органнары хезмәткәрләренең акчалата тәэмин ителеше, шулай ук Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән даими характердагы өстәмә түләүләр һәм азык-төлек белән тәэмин итү;

- хәрби хезмәттән, Россия Федерациясе Эчке эшләр органнарыннан, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләреннән һәм органнарыннан, Россия Федерациясе таможня органнарыннан, хокук саклау хезмәтенең башка органнарыннан азат ителгәндә бер мәртәбә бирелә торган пособие;

- эш бирүчеләр тарафыннан үз хезмәткәрләренә, шул исәптән инвалидлык яисә яшь буенча пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә эштән киткән элеккеге хезмәткәрләренә күрсәтелә торган матди ярдәм;

- авыр тормыш вәзгыятен раслаучы, түләү, дәвалау, кыйммәтле дарулар яисә медицина әйберләре сатып алу, операция үткәрү һәм операциядән соңгы чорда реабилитацияләү кирәклеген раслаучы документлар - сәламәтлек саклау учреждениеләреннән, оешмаларыннан;

- мөрәҗәгать итүчегә һәм (яисә) аның гаиләсенә янгын, су басу яисә башка табигый бәла – каза аркасында җитди зыян китерүнераслый торган документлар - Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгыннан, Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгыннан яисә алар карамагындагы учреждениеләрдән, оешмалардан;

- банктагы счет реквизитларын күрсәтеп, банк кертеме шартнамәсе (яки саклык кенәгәсе).

Тиешле документлар мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән максатларга карап тапшырыла. Керемнәр турында белешмәләр керем чыганакларының булуына (булмавына) карап

тапшырыла. Документларның һәм белешмәләрнең күчермәләре бер нөсхәдә тапшырыла.

7. Бүлеп бирелгән акчалар үзләштерелмәгән, алучы тарафыннан бирелгән акчалардан максатчан файдалану бозылган, дөрес булмаган белешмәләр булган документлар тапшырылган очракта, акчалар Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

8. Акчаларны бирүне туктату һәм (яисә) кире кайтару турында карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты кабул итә.

9. Акчаларны кире кайтару Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының территориаль бүлегендә ачылган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының шәхси счетына күчерү юлы белән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының язма таләбе буенча бәхәссез тәртиптә гамәлгә ашырыла.

10. Акчаларны ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартканда, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә түләтелә.

11. Башкарма комитет квартал саен район Советына Резерв фонды акчаларының тотылуы турында хәбәр итә.